**САБИРОВА Л.Р.**
*кандидат филологических наук, доцент*
*Казанский (Приволжский) федеральный университет*

**ЗАЙНУТДИНОВА И.И.**
*студент*
*Казанский (Приволжский) федеральный университет*

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ И АУДИТОРИЯ: НОВЫЕ МЕТОДЫ И СПОСОБЫ РАБОТЫ (НА ПРИМЕРЕ ТАТАРОЯЗЫЧНЫХ ПЕРЕДАЧ НА ТЕЛЕКАНАЛЕ “ТАТАРСТАН-НОВЫЙ ВЕК”)

**Аннотация.** Статья посвящена актуальной проблеме – изучению новых методов и способов работы на телевидении. На примере татароязычных телепередач, авторы показали самые актуальные методы работы с аудиторией на региональном телевидении. Проанализировав самые популярные программы, пришли к выводам, что на сегодняшний день телекомпания «Татарстан-Новый век» работает в ногу со временем, использует самые передовые технологии и методы для привлечения аудитории.

**Ключевые слова:** региональное телевидение, работа с аудиторией, новые методы, журналистика.

**Abstract.** The article is devoted to studying new methods and ways of working on television. For example Tatar-speaking television, the authors showed the actual methods of work with the audience on regional television. After analyzing the most popular program came to the conclusion that today the broadcasting company "Tatarstan-New century" works in step with the times, uses the most advanced technology and techniques to attract audience.

**Keywords:** regional television, audience development, new methods of journalism.

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ ҺӘМ АУДИТОРИЯ: ЭШЛӘҮДӘ ЯҢА МЕТОД-АЛЫМНАР (“ТАТАРСТАН-ЯҢА ГАСЫР” КАНАЛЫНДА ЧЫГУЧЫ ТАТАРЧА ТАПШЫРУЛАР МИСАЛЫНДА)

Бүгенге көндә татар телевидениесе хакында күп төрле фикерләр ишетергә мөмкин. Фикерләрнең бик азы мактау сүзләре, күпчелек фикерләр телевизион тапшыруларның сыйфатсызлыгы, кызыксыз булулары хакында дияргә кирәк.

Әмма татар телендә чыгучы тапшыруларның барысын да кызыксыз дип әйтү урынсыз булыр иде. Соңгы берничә ел эчендә татар телевидениесе шактый зур үзгәрешләр кичерде, тележурналистиканың төрле алымнарын кулланып, күп төрле яңа формаларда эшли башлады. Телевидениедә мавыктыргыч, күңелле, шул ук вакытта файдалы тапшырулар саны сизелерлек артты. Милләтебезнең асыл сыйфатларын, гореф-гадәтләрен, уен-йолаларын, бай әдәбиятыбызның мирасын телевизор караучыларга матур итеп тәкъдим итәрдәй тапшырулар барлыкка килүе аеруча нык сөендерә. Урта буын вәкилләрен генә күз уңында тотып эшләмиләр хәзер, балалар, яшүсмерләр өчен дә бик күп мәгълүмат һәм белем алырдай тапшырулар зәңгәр экраннарга чыга.

Яңа тапшыруларның барлыкка килүе кызыклы формалар, яңа алымнар уйлап табуга да этәргеч бирә. Заман белән бергә атлау җиңел түгел, ләкин телевидениедә эшләүче журналистлар телевизор караучы тамашачының күңелен күрү өчен бик тырыша. Әңгәмә, бәхәс, ток-шоу форматында эфирга чыгучы берсеннән – берсе кызыклы тапшырулар әзерли. Интеллектуаль уеннар, ярыш форматындагы тапшырулар – бүгенге көндә татар телевидениесе өчен бу формалар да инде ят түгел.

Милли телевидениебездә үзгәрешләр чоры бара дисәк тә, ялгыш булмас. Телевидениенең яңа форматка күчүе, төрле экспериментлар, яңа алымнар күзәтелү моңа ишарә. Кемнәрдер бу үзгәрешләрне замана таләбе дип атый, кемдер татар телевидениесенең үсеше дип бәяли, кемнәрдер тәнкыйть утында тота.

Тамашачыны шаккатыру, җәлеп итү безнең заманда бер дә җиңел эш түгел. Шуңа күрә аудиторияне саклап калу өчен телевидениедә эшләүчеләргә күп көч куярга туры килә.

Яңа алымнар һәм үзенчәлекле формалар эзләү – ул бүгенге көн журналистикасының төп таләбе булып тора.

Газета жанрларыннан ук башлангыч алган традицион булган телевизион жанрлар бүгенге көндә күзгә күренерлек зур үзгәрешләр кичерде. Аларны традицион булган жанрлар калыбына салып карау урынсыз булачак. Хәзерге вакытта “жанр” сүзен “формат” сүзе алмаштырды. Әмма “жанр” төшенчәсен сызып ташлау мөмкин эш түгел, чөнки ул журналистиканың нигезен алып тора. Форматлар арасында яңалыклар, сериаллар, ток-шоу, реалити-шоу, телевизион уеннар өстенлек итә.

XX гасыр азагында традицион булган гаммәви мәгълүмат чаралары системасында – матбугатта, радиода, телевидениедә компьютер һәм телевизион технологияләр белән бәйле яңа төр коммуникацияләр формалашты. Бу, беренче чиратта, кабельле һәм спутниклы телевидение, радио белән телевидениене

Интренет аша тыңлау һәм карау, шулай ук мәгълүматны саклау һәм таратуга бәйге башка бик күп төрле технологияләр.

Техник үсеш алга барган саен, телевидениедә дә үсеш сизелерлек арта. Мәсәлән, бүгенге көндә тамашачылар телевизор экраннарыннан тапшыруны күзәтеп кенә калмыйча, аның барышына, ни рәвешле дәвам итәчәгенә тәэсир итә ала. Сорау – җавап тибындагы телевизион уеннарда катнашу мөмкинлеге, турыдан – туры эфирда барган әңгәмәләргә кушылу – болар инде бүгенге көн телевидениесе өчен гадәти хәл һәм моның белән хәзер беркемне дә шаккатырып булмый.

Узган берничә ел эчендә популярлашып киткән төрле телевизион конкурсларда нәтиҗәне тамашачы чыгару да бүгенге көндә мөмкин эш. Телефон ярдәмендә үзенә ошаган сәнгать номеры (җыр, бию яки башкасы), төрле командалар, катнашучылар өчен тавыш биреп, телевизион бәйгенең ничек тәмамланасын онлайн режимда нәкъ менә тамашачы үзе хәл итә, ягъни зәңгәр экраннар аша баручы программага өеннән чыкмый гына үз өлешен кертә.

Соңгы елларда Россия регионнарында эфир тапшыруларын әзерләү технологиясе һәм тәкъдим итү алымнары белән бәйле телевизион революция килеп чыкты дияргә дә мөмкин.

Төрле формаларның барлыкка килүе, тапшыруларны тәкъдим итүнең моңарчы күзәтелмәгән алымнары булдырылу телевизион журналистикага яңа сулыш өсти. Әлеге яңалыкларга омтылу телевидение үсешенә дә зур өлешен кертә.

Телевидениенең нигезендә ике төп фукцияне билгеләргә була – мәгълүмати һәм күңел ачу функцияләре.Телевизор караучы тамашачының игътибарын җәлеп итүнең төп стратегиясе булып бүгенге көндә үзебезнең илдә төшерелгән сериаллар, күңел ачу тапшырулары һәм төрле шоу программалар тора. Шуңа күрә күңел ачу функциясенә эфирда урын күбрәк бүленә.

Әгәр бүгенге көн телевидениесендәге төп үзгәрешләрне билгеләсәк, алар күңел ачу, юмор, реаль тормыштагы вакыйгаларны яктыртучы программалар белән бәйле булачак. Бернинди тыюларсыз, ничек бар – шулай күрсәтелүче тормышчан вакыйгалар турында булган программалар да алдагы рәтләрдә бара. Хәзерге вакытта нәкъ шундый телевидение генә максималь санда аудиторияне үзенә каратып тота ала.

Күңел ачу функциясенә күбрәк игътибар бирелгән очракларда да, телевидение җәмгыятьнең социаль-психологик хәленә йогынты ясаучы көчле ресурс булып тора. Төрледән-төрле күңел ачу тапшырулары белән беррәттән телеэкраннарга тамашачының интеллект үсешенә файда китерүче тапшырулар да тәкъдим ителә хәзер.

**“Татарстан-Яңа гасыр”** каналының “Дубль-video” дубляж студиясе тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителгән мультипликацион фильмнар, сериаллар белән бергә безнең һәм чит ил кинематографиясенең иң яхшы үрнәкләрен дә күрергә була. Эфирда кырыктан артык даими тапшыру һәм программа бар.

**“Татарстан-Яңа гасыр”** каналының көчле сигналын Татарстанның һәр районында тотып була. Мәскәү, Екатеринбург, Ижау, Әлмәт, Төмән шәһәрләрендә хәбәрчеләр пунктлары белән беррәттән каналның Башкортстанда үзенең реклама бүлеге эшләп килә. Телеканалның тапшырулары www.tnv.ru яңартылган сайтында online режимында трансляцияләнә” [1].

2009 нчы елның сентябрь аенда “Татарстан-Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе эчендә балалар һәм яшьләр өчен аерым бер канал эшли башлады. Хәзер барлык балалар, үсмерләр һәм яшьләр тапшырулары “Яшь ТНВ” каналы кысаларында эфирга чыга.

“Яшь ТНВ” каналы кече яшьтәге аудитория өчен – мәктәпкәчә, мәктәп яшендәге һәм яшүсмер балаларга юнәлдерелгән телетапшырулар системасын тәшкил итә. Әлеге каналның максаты балаларны төрле яклап тәрбияләү, белемгә, туган телгә, туган җиргә мәхәббәт уяту. Форма ягыннан балалар телевидениесе гаять киң: әкият, маҗаралы тапшырулар, фәнни-фантастик, фәнни-популяр фильмнар, кызыклы кешеләр белән очрашулар, уеннар, бәйгеләр, мультфильмнар – кечкенә тамашачыга хезмәт итүче жанрлар бик күп.

Әлеге каналда күпчелек тапшыруларның алып баручылары да – балалар. Аудиториянең игътибарын җәлеп итү өчен бу бик файдалы алым булып тора. Шулай ук яшь тамашачыларга мәгълүматны үзләренең яшьтәшләре булган алып баручылардан ишетеп белү дә күпкә кызыграк. Өстәвенә, күпчелек балалар, яшүсмерләр өлкәннәрнең акыллы сүзләрен, киңәшләрен тыңлап утырырга яратмый торган була. Кирәкле мәгълүматны үзләре кебек үк балалар авызыннан ишетү аларда зур кызыксыну уятып кына калмый, аны үзләштерүгә һәм кирәк булган очракта тормышта кулланып карарга да этәргеч бирә.

Журналистикада, аерым алганда телевидениедә, аудиториянең яшен, психологик үзенчәлекләрен истә тотып эшләү зарур. Шул очракта гына тамашачының күңелен яулап булачак һәм эшнең нәтиҗәләре күзгә күренә башлаячак.

Милли телевидение бүгенге көндә аудиторияне кече яшьтән тәрбияли башлый дип курыкмыйча әйтергә мөмкин. “Яшь ТНВ” каналында нәни тамашачы өчен күңелле тапшырулар белән берлектә, акыл эшчәнлеген арттыра, уйланырга мәҗбүр итә торганнары да эфирга чыга. Мисал өчен, барыбыз да яратып өлгергән “Тамчы-шоу” интеллектуаль-күңел ачу тапшыруын гына алыйк. Формасы ягыннын

ул безнең телевидение өчен яңа форматта – уен форматында эшли. Тапшыруның максаты республикабызда яшәүче сәләтле балаларны ачыклау, берләштерү, белемгә, китап укуга мәхәббәт уяту, кечкенәдән татар зыялыларын үстерү. Телевизион уенда 6,7,8 сыйныф укучылары катнаша. Алар һәрберсе гыйбрәтле, кирәкле һәм файдалы китаплар белән бүләкләнә. Бу, әлбәттә, үсеп килүче яшь буынга матур әдәбият әсәрләрен өйрәнергә зур этәргеч булып тора. Интеллектуаль-күңел ачу уенының максаты:

- география, әдәбият, сәнгать, татар мәдәнияты һәм тарихы буенча сорауларга дөрес җавап бирү;
- Казан шәһәренең тарихи урыннарын, һәйкәлләрен белү, алар белән якыннанрак танышу (Видеотабышмак);
- әдәбиятыбызның күренекле әдипләренең әсәрләре белән танышу, аларның эчтәлеген бергәләп анализлау;
- татар халкының мәкальләрен мәктәп укучыларына, гомумән, милләтебез балаларына пропагандалау.

Белемне арттыручы әлеге тапшырулар телевизор караучылар өчен файдалы да, шул ук вакытта күңелле дә булган формада эшләнә. Үзара көч сынашкан ике командага кушылып, тамашачылар үзләре дә ярышырга, тапшыруда тәкъдим ителгән биремнәрне үтәргә мөмкин [2].

“Яшь ТНВ” каналында эфирга чыгучы телетапшырулар арасыннан тагын бер игътибарга лаеклы дип атарга мөмкин булганы – “1001 җавап” тапшыруы. Әлеге тапшыруның үзенчәлеге – аны балаларның үзләре алып баруы. Кечкенә балалар сөйләвен өлкән яшьтәге тамашачы да яратып тыңлый, шуңа күрә әлеге тапшыруның аудиториясенең яшен чикли дип һич кенә дә әйтеп булмый. Тапшыруның үзенчәлеге, форма яңалыгы буларак аның студиядә генә түгел, ә тематикасына туры китереп, төрле җирләрдә төшерелүен, нәни алып баручыларның үзләрен сынап карап, эксперимент рәвешендә тамашачыга өйрәнгән теманы практикада күрсәтә алу мөмкинлеген атарга кирәк. Тапшыруның мондый формада әзерләнүе яшь тамашачылар һәм аларның эти-әниләре өчен бик файдалы. Тәрбияви, интеллектуаль һәм кызыклы булуы, авыр темаларның да балалар теле белән җиңел аңлатып бирелүе аудиториянең кызыксынуын арттыра.

Форма ягыннан милли тележурналистикабыз өчен яңалык алып килүче тапшыру буларак, “Күчтәнәч”не дә әйтеп узарга кирәк. Бу тапшыруда балаларга әкият, мультфильмнар күрсәтеп кенә калмыйча, алардан килгән хатларны да укыйлар, бүләк итеп ясаган рәсемнәрне, видеосәламнәрне дә күрсәтәләр. Тапшыруның үзенчәлеге сөйләшә белүче уенчыклар – Йомшаккай белән Актәпи. Алар еш кына төрле мәктәпләрдә, балалар бакчаларында кунакта булып, кызыклы

сюжетлар да төшереп алып кайта. Күчтәнәчнең алыштыргысыз алып баручылары Дәү әни белән Дәү эти. Аларны барлык татар балаларының әби-бабасы дип атап йөртергә дә була. “Күчтәнәч” тапшыруы бик кирәкле, файдалы тапшыру. Ул “ТЭФИ Регион 2009” Бөтенроссия телевизион бәйгесендәге “Балалар өчен тапшырулар” номинациясендә җиңү яулады.

Үзенчәлекле формада әзерләнүче тапшырулар рәтенә “Һөнәр” тапшыруын да кертергә кирәк. Әлеге тапшыруның асылында һөнәр алмаштыру, ягъни журналистның эксперимент рәвешендә үзен башка һөнәр иясе буларак сынап каравы тора. Кондитер, укытучы, дизайнер, тимерче һәм башка бик күп төрле һөнәрләрне үзләштереп карадылар тапшыруның алып баручылары. Шул рәвешле алар абитуриентларга киләчәктә һөнәр сайларга ярдәм итә, теге яки бу өлкәгә алынганчы, нинди киңәшләрне истә тотарга кирәклеген аңлата. Тапшыруның яңалыгы – һөнәри белем алган, тәҗрибә туплаган белгечләрнең үз эшләре белән кызыклы, үзенчәлекле итеп таныштырулары, тамашачы хозурына үзләренең гадәти эш көненнән, эш тәртибеннән нинди дә булса өзекне тәкъдим итүләре игътибарга лаек. Соңгы вакытларда тапшыруга тагын бер үзенчәлек өстәлде: хәзер аны төрле йолдызлар – театр артистлары, җырчылар, биючеләр алып бара. Тапшыруларны төрле өлкәдән булган танылган кешеләр алып баруы аны кабатланмас итә. Эксперимент рәвешендә аларны башка өлкәдә, төрле һөнәр ияләре буларак сынап карыйлар. Яраткан артистларының телеэкраннар аша үзләрен башка һөнәрдә сынап карауларын күзәтү, алардан файдалы киңәшләр алу аудиториянең кызыксынуын тагын да арттыру максатыннан эшләнгән. Бу төр алымны куллану тапшыруга аерым бер күңеллелек өсти [3].

“Яшь ТНВ” каналында баручы “Мәктәп” тапшыруы да тамашачы өчен кызыклы, файдалы тапшыруларның берсе. Тапшыруның һәрберсе аерым бер мәктәпкә багышлана. Республикабызның төрле районнарында, шәһәрләрендә урнашкан мәктәпләр белән анда белем алучы укучылар үзләре таныштыра. Журналист сөйләгәннәрне генә тыңлап калмыйча, биредәге укыту системасы, мәктәпнең эчке дөньясы, укытучылары турында укучыларның үзләреннән ишетү күпкә кызыклырак. Тапшыруның укучылар әзерләгән төрле җырлар-биюләр белән дә үрелеп баруы аны тагын да баетып җибәрә. Әлеге тапшыру аша телевизор караучылар мәктәп тарихы белән генә түгел, ул урнашкан төбәк тарихы белән дә таныша ала. Шулай ук тамашачылар мәгариф өлкәсендә булган күп кенә яңалыклар, укыту системасындагы үзгәрешләр турында да хәбәрдар була.

“Яшь ТНВ” каналының күптән түгел генә эшләп киткәнен искә алсак, аның бүгенге көндә алып барган эшчәнлегенә сокланырга, ирешкән уңышларына карап шатланырга мөмкин. Кыска гына вакыт аралыгында балалары өчен югары

дәрәҗәдә эшләүче канал булдырылу бүгенге көн татар телевизион журналистикасына аңа сулыш алып килде. Моннан берничә ел элек телевидениедә балаларны күрү гаҗәп хәл итеп кабул ителсә, хәзер исә бу гадәти күренеш. Телевизон журналистикада кече яшьтән үзләрен сынап карау мөмкинлеге алган яшь журналистлар киләчәктә милли телевидениебезгә тагын да яңа проектлар, тапшырулар әзерләп, тамашачыны шатландыра алыр.

Хәзерге вакытта “Татарстан-Яңа гасыр” телеканалында реалити-шоудан кала барлык форматтагы тапшырулар да бар. Аның әлегә кадәр тележурналистикабызга килеп кермәвен менталитетыбызга бәйләп аңлатырга да, милли журналистикада бу форматка алынырдай кеше булмавы белән бәйләп карарга да була.

Үзенең 10 еллык юбилей уңаеннан **“Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе” ААҖ “ТНВ-Планета”** каналын булдырды. 2012 елның 15нче июненнән башлап “**ТНВ-Планета”** каналы үз эшен башлап җибәрде. 2012 елның 30нчы августыннан алып канал планлы рәвештә эшләп китте.

**“ТНВ-Планета”** – Россия Федерациясе төрле регионнарында, БДБ илләрендә, чит төбәкләрдә гомер кичерүче Татарстанны тарихи ватаннары дип исәпләүче күпсанлы милләттәшләребезне берләштерүче мәдәни-мәгърифәтче спутник телеканалы.

“ТНВ-Планета” телеканалының максатлары:

- бөтен Россия күләмендә һәм галәм дәрәҗәсендә Татарстан республикасын таныту;
- регионның куәтле икътисадын, мәдәниятен һәм спорт потенциалын яктырту;
- татар телен үстерү һәм саклап калу;
- милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне барлау һәм аларны киләчәк буыннарга югалтмыйча җиткерү;
- Россия территориясендә һәм чит төбәкләрдә яшәүче татар диаспораларын берләштерү, аларның мәдәни һәм рухи байлыкларын яңарту. [4].

“ТНВ-Планета” каналы тәүлек әйләнәсе эшли. Телевизион программа нигезендә 8 сәгатьлек блоклар ята. Блокта “ТНВ-Планета” каналының татар телендә булган иң яхшы спектакльләре, концертлары, фондта саклանучы тапшырулар урын алган.

Дөньядагы барлык телевизион тапшыруларны, һәр телеканалларның форматы үзгә булуы очрагын гына истә тотсак та, берничә уртак төркемгә бүлеп каравыбыз бик зур хата булачак.Телевизион тапшыру әзерләү – иҗади эшчәнлекнең иң катлаулы төрләренең берсе. Мәгънәви тирәнлеге һәм кулланучыга йогынты ясавы буенча аны бары тик китап белән генә чагыштырып булыр иде.

Милли телевидениебездә яңа формаларны, алымнарны күп очракта балалар һәм яшьләр, күңел ачу тапшыруларында, мәгърифәтчел тапшыруларда очратырга мөмкин, спорт тапшыруларында, публицистик тапшыруларда яңалык булырлык алымнар әлегә күренми. Моның ник шулай булуын аңлау да авыр түгел: бүгенге көндә телевизор аудиториянең күпчелек проценты өчен күңел ачу вазыйфасын башкара. Шуңа күрә тамашачыны җәлеп итү максатыннан телеведениедә эшләүче журналистлар да яңадан – яңа алымнар эзли, төрле формаларга мөрәҗәгать итә.

Яңа формалар уйлап табу, эзләнү бүгенге аудиториянең журналистика алдына куйган төп таләбе. “Татарстан-Яңа гасыр” каналы да әлеге таләпне үтәргә тырыша, биредә хезмәт куючылар аудиториянең һәр гозерен истә тотып эш итәргә тырыша.

Бүгенге көндә милли телевизион журналистикага килеп кергән яңалык дип ток-шоу форматын атарга мөмкин. Безнең тележурналистикада күптән түгел барлыкка килсә дә, аның барлыкка килүе узган гасырның 60 нчы елларына карый.

Әлеге форматның матур үрнәге булып, “ТНВ-Планета” каналында татар телле аудитория өчен эфирга чыгучы“Яшьләр on-line” мәгълүмати-күңел ачу, аналитик ток-шоуы эшләп килә иде. Кызганыч, ул чыгудан туктады [5].

Бүгенге көндә “Яшьләр-online”ны “Таяну ноктасы” тапшыруы алмаштырды. Асылда шул ук нигез булса да, алар аерыла. Беренчедән, тапшыруда бер генә алып баручы. Икенчедән, тәкъдим ителгән темага үз фикерен белдереп, килгән кунаклар төймәләр ярдәмендә хәбәр итә. Яшел – димәк, ризалаша, кызыл – димәк каршылык белдерә, ак икән, димәк ул битараф. Өченчедән, тапшыруда кискен проблемалар һәм актуаль сораулар күтәрелә. Алып баручы да үзен иркен тота һәм шулай ук кыю рәвештә сораулар бирә.

Мәсәлән, 2017нче елның 13нче апрелендә дөнья күргән “Таяну ноктасы” тапшыруы Татарстанның мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттаховның күчмә утырышта икетелле укытучылар әзерләү буенча Казан федераль университетына киске тәнкыйть белдерүенә карата әзерләнгән иде [6].

Ток-шоуның бер төре буларак бүлеп карарга күнеккән әңгәмә жанрында баручы тапшырулар да бар бүгенге көндә “Татарстан-Яңа гасыр” каналында. Шуларның иң матур үрнәге булган туры эфирда баручы “Мәдәният дөньясында” тапшыруы шундыйлардан. Тапшыруның алыштыргысыз алып баручысы Гүзәл Сәгыйтова. “Мәдәният дөньясында” тапшыруында көн үзәгендәге торган темалар яктыртыла, Татарстанда мәдәният үсеше, ватандашларыбызның рухи кыйммәтләре, җөмһүриятнең мәдәни потенциалы турында әңгәмәләр алып барыла. Студия кунаклары арасында танылган язучылар, музыкантлар, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, министрлык һәм ведомство вәкилләре була.

“Мәдәният дөньясында” тапшыруында аудитория белән онлайн режимда аралашу мөмкинлеге дә тудырылган. Тамашачылар тапшыру барышында студиягә шалтыратып, үзләре дә кызу бәхәскә кушылып, фикерләрен җиткерә ала. Шулай ук килгән кунакларга кызыксындырган сорауларын биреп, җаваплар да табалар. Әмма ни кызганыч, әлеге тапшыру күптән түгел эфирга чыгудан туктады [7].

Үзенчәлекле формада әзерләнгән тапшырулар арасында “ТНВ-Планета” каналында баручы “Кичке аш” тапшыруы да игътибарга лаеклы булып тора. “Кичке аш” – гаилә белән утырып карар өчен эшләнгән кызыклы тапшыру. Ул белемне арттыручы тапшырулар рәтендә тора. Алып баручылар – Резедә Хәсәнова һәм Энҗе Әхмәтҗанова. Тапшыруда кичке аш әзерләү, табын артында гаилә белән сыйлану күренеше тасвирлана. Алып баручылар иҗади коллективларда, рестораннарда, Татарстанның төрле авылларында, шәһәрләрендә яшәүче гаиләләрдә булып, кичке аш әзерләү серләрен ача. Төрле халыкларның милли ризыкларын әзерләргә өйрәтүче, шул ук вакытта аларның килеп чыгышы, организмга булган файдасы хакында да мәгълүмат җиткерә [8].

Тагын бер игътибарга лаек тапшыру – “Адымнар”. Мәгълүмати-аналитик тапшыру буларак, аның төп нигезен сәясәт, җәмгыять проблемалары алып тора. Тапшыруның иң төп үзенчәлеге – алып баручы Сәрия Хәбибуллина белән аның ярдәмчесе әкияти персонаж – аксакал Шомбай. Янә бер алым – тапшыру эчендә тапшыру, ягъни “Адымнар”ның үзәгендә күрсәтелүче “Кадак” һәм “МММ+” сәхифәләре [9].

“ТНВ-Планета” каналының йөзек кашы булган “Халкым минем” тапшыруы жанры буенча очерк дип атап булыр иде. Бүгенге телевидениедә әлеге жанр сирәк күренеш. Тапшыруның алып баручысы Ләйсәнә Садретдинова дөньяның төрле почмакларында сибелеп яшәүче татар милләтеннән булган шәхесләрне эзләп табып, алар яшәгән төбәкләргә сәяхәт итә. Шул рәвешле ул тамашачыларга әлеге җирләрнең кешеләре, табигате, мәдәнияте хакында да сөйли, милләттәшләребезнең тормышлары, чит якларда алып барган эшчәнлекләре турында да җиткерә [10].

“Татарстан-Яңа гасыр” телеканалында махсус проектлар да эфирга чыга. Республикабызда булган зур чара – вакыйгаларны, фестиваль – тантаналарны яктыртыла әлеге телевизион тапшыруларда. Мисал өчен, “Сәләт” яшьләр оешмасының 20 еллык юбилее уңаеннан аңа багышлап әзерләнгән тапшыру игътибарга лаек. Әлеге тапшыру “Сәләт” оешмасының юбилей тантанасы вакытында төшерелде. Тапшыруны татар телендә Венера Иванова алып бара.

Шулай ук аудитория өчен бик кызыклы булган махсус чыгарылышларның берсе – президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановның Республикабыз белән җитәкчелек итүенә 5 ел тулу уңаеннан әзерләнде. Җитди темага кагылышлы булса

да, тапшыру җиңел итеп әзерләнгән. Балалар бакчасы күренеше белән башланып китә ул. Анда тәрбияләнүче нәниләрдән президентыбыз хакында интервью алалар. Балаларның фикерен сорашу алымы кулланып, тамашачыны алдан ук тапшыруның күңелле итеп әзерләнү хакында белгертеп куялар.

Махсус проектлар арасында шулай ук Республикабызда узырылучы “Ак чәчәкләр – Врач года” дип аталучы табиблар, “Мисс Татарстан – 2014” бәйгесенә багышлап эшләнгән чыгарылыш, “Болгар” радиосының II милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасыннан әзерләнгән, шәһәр Сабантуенда төшерелгән репортажлар да бар.

Махсус проектлар телевизор караучылар арасында бик популяр. Өйдән чыкмыйча гына Республика күләмендә уздырылучы чараларны үз күзләре белән күрү бәхетенә ирешә алар.

Шулай ук “Татарстан-Яңа гасыр” каналы спорт матчларын, Ураза Гаете, Корбан Гаете вакытында мәчетләрдә узган бәйрәм намазын, вәгазьләрне турыдан-туры трансляцияли. Техникага бәйле рәвештә бу як та үсеш алды. Бүгенге көндә алга китеш шактый нык сизелә.

“Татарстан-Яңа гасыр” телеканалының аудиториясен ачыклау өчен анда барган тапшыруларга анализ ясап карау җитә. Ике дәүләт телендә хезмәт күрсәтүче телеканал аша һәркем үзенә кирәкле тапшыруны табып карый ала. Балалар, яшьләр, өлкәннәр аудиториясенә туры килердәй, хатын-кызлар, ир-атлар, спорт сөючеләр өчен кызыклы тапшырулар урын алган. Шулай ук күңел ачу тапшырулары һәм белемне арттыручы тапшырулар эфирга чыга. Бу тагын бер тапкыр “Татарстан-Яңа гасыр” телеканалының һәркемгә туры килә торган, уникаль канал икәнен исбатлый.

Федераль каналлардан аермалы буларак, “Татарстан–Яңа гасыр” телеканалының даими тамашачысын бер төркемгә генә караучылар алып тормый, төрле яшьтәге, җенестәге тамашачы өчен каралган тапшырулар бүгенге көндә актуаль булган мәсьәләләрне яктырта, көн кадагында булган проблемаларга чишелеш эзли.

“Татарстан-Яңа гасыр” каналының аудиторияне җәллеп итү буенча төп коралы – аның һәркемгә яраклашкан һәм һәрдаим үсештә булу. Бер адымда таптанып тормыйча, яңа формаларга өстенлек биреп, яңадан-яңа тапшырулар уйлап табып, аларны кызыклы алымнар белән тәкъдим итү киң аудиторияне җәлеп итәргә һәм сакларга ярдәм итә.

*Әдәбият*

1. “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе сайты. – URL: www.tnv.ru.

2. Тамчы шоу // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2017. 28 апр.. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/molodezhnye/tamchy-shou/?p=&idVideo=56557#videoanc.

3. Һөнәр // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2016. 22июнь. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/molodezhnye/n_r/?p=&idVideo=50701#videoanc.

4. “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе сайты. – URL: www.tnv.ru.

5. Яшьләр он-лайн // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2016. 28 авг. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/molodezhnye/yash_l_r_on-line/?p=&idVideo=51892#videoanc.

6. Таяну ноктасы // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2017. 13 апр. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/tok-shou/tayanu_noktasy/ ?p=1&idVideo=56057 #videoanc.

7. Мәдәният дөньясында // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2016. 28 авг. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/tok-shou/m_d_niyat_d_n_yasynda/?p= &idVideo =51921#videoanc.

8. Кичке аш // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2017. 19 март. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/poznavatelnye/kichke_ash/?p=&idVideo=55617 #videoanc.

9. Адымнар // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2017. 29 апр. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/informacionnye/adymnar/?p=&idVideo= 56509 #videoanc.

10. Халкым минем // “Яңа Гасыр” телерадиокомпаниясе. 2017. 22 апр. – URL: http://tnv.ru/main/katalog/prosvetitel_skie/halkym_minem/p=&idVideo=56612#videoanc.